КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 29 декабрь г.Казань № 1292

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Сәламәтлек саклауны үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасының аерым чараларын тормышка ашыруны финанслар белән тәэмин итү тәртибен һәм Медицина хезмәткәрләренә (табибларга, фельдшерларга) бер тапкыр компенсация түләүләре бирү тәртибен раслау турында» 2017 ел, 13 июнь, 372 нче карары белән расланган «Сәламәтлек саклауны үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасының аерым чараларын тормышка ашыруны финанслар белән тәэмин итү тәртибенә үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Сәламәтлек саклауны үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасының аерым чараларын тормышка ашыруны финанслар белән тәэмин итү тәртибен һәм Медицина хезмәткәрләренә (табибларга, фельдшерларга) бер тапкыр компенсация түләүләре бирү тәртибен раслау турында» 2017 ел, 13 июнь, 372 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 28 февраль, 127 нче; 2018 ел, 25 сентябрь, 852 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган «Сәламәтлек саклауны үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасының аерым чараларын тормышка ашыруны финанслар белән тәэмин итү тәртибенә түбәндәге үзгәрешне кертергә:

4 пунктның «г» пунктчасында «таркау склероз белән» сүзләрен «гемолитик-уремик синдром, системалы башлану белән белән яшүсмерләр артриты, I, II һәм IV типтагы мукополисахаридоз белән,» сүзләренә алмаштырырга.

2. Бу карар 2019 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин